ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422176

Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
22 ноябрь 2018 ел №19

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән «19» ноябрь 2018 елдагы № 901 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Албай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Крешков И.П.

Татарстан республикасы Мамадыш
муниципаль районы, Албай авыл
җирлеге башкарма комитетының
2018 елның 22 ноябре 19 № лы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,**
**Албай авыл җирлеге гражданнарының**
**үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Албай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019 нчы елның 28 нче февраленә кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) вакытлыча эшкә яраксызлык,

б) хезмәт буенча командировка,

бер айдан артык булмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарынамуниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында,Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгаруһәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыуставында бигеләнгән тәртиптә,шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыруяки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы

Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру,  акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитеты  кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 22 нче ноябрь 19 нчы № лы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитеты бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында

БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.

______________________________________________________________________

Адрес:

______________________________________________________________

Нигезләмә: Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 921 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре турында”

Сезгә 2019 елның 28 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум чараларын тормышка ашыру өчен 400 сум күләмендәге түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы Татарстан Республикас НБ бүлеге БИК049205001

Сч. № _________________________

Кабул итеп алучыСч. № № 40101810800000010001

ИНН 1626008921

КПП 162601001

КБК 605 117 14030 10 0000 180 ОКТМО 92638403

Түләүнең билгеләнеше

Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче __________________ __________________________________________

М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитеты бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне 400 сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.

Түләүченең Ф.И.Ә.и.

______________________________________________________________

Адрес:

_____________________________________________________________________________

Кабул ителде «__» ________________ 20__ ел.

__________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Албай авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*